**Г.Г. Әхмәдгалиева**

**Алабуга дәүләт педагогика университеты**

# Хәсән Туфан шигырьләрендә стилистик синонимнар

Чынбарлыкка төрле мөнәсәбәт белдерү ягыннан аерылып торган синонимнарны эмоциональ-экспрессив синонимнар диләр: *ялагайлану – юмакайлану, юхалану, тәлинкә тоту; киреләнү – тискәреләнү, үзсүзлеләнү, карышу.* [4, б.42]. Төрле стильләрдә кулланылганга күрә, аларны стилистик синонимнар дип тә йөртәләр.

Китап теле һәм җанлы сөйләү теле арасында элек-электән аерымлыклар булган. Бу алардагы үзара синоним сүзләрнең кулланылуында да ачык күренә [6, б.110]. Синонимнарның бик күбесе стилистик яктан аерымлана, ягъни бер үк төшенчәне белдергән сүзләрнең берсе бер төр сөйләм стиленә, икенчесе икенче төр сөйләмгә карый. Гадәттә, китап сүзләре сөйләмнең югары, тантаналы булуы, күтәренкелеге белән бәйләнгән була. Стильнең түбәнрәк, гадирәк, халыкчанрак булуы җанлы сөйләм, сөйләшү теле өчен хас.

Хәсән Туфан шигырьләрендә без стильара (нейтраль) һәм китапча сүзләрнең синоним булып килеп, янәшә кулланылуын мисаллар нигезендә күзәтә алабыз.

*Чәчәк ата ул,*
*Чәчәк ата ул,*
*Йокысыз төндә,*
***Төрмәләр,***
***Зинданнар** эчендә...*
(«Бер генә сүз, бары бер генә»)

Тарихи яктан караганда, әлеге синонимнарның барлыкка килүен телнең алынма сүзләр исәбенә баюы белән аңлатырга мөмкин. Бүгенге көндә *төрмә* сүзе – нейтраль, гомум кулланылыштагы сүз, ә *зиндан* күбесенчә китап телендә, югары стильдә очрый. Бу синонимик рәттәге *төрмәләр, зинданнар* синонимнары борынгы заманнарда да (*зинданнар эчендә),* хәзерге

заманда да *(төрмәләр эчендә)* ирекләреннән мәхрүм булган тоткыннарның телләрен золым кылучылар, җәзалаучылар тыя алмауларын күрсәтеп, *сүз*нең ирексезлектә дә чәчәк атуына ишарә ясый.

*Көч – куәт – дәрман – җегәр – гайрәт – кодрәт* синонимик рәтен аерып карыйк. Әлеге синонимнар мәгънәләре ягыннан бер-берсенә якын торалар, ләкин аларны тәңгәл киләләр дип әйтеп булмый. *Дәрман, кодрәт, гайрәт* синонимнары образлылыкка тартым, эмоциональ-экспрессив эчтәлекләре бай булганга, алар еш кына тотрыклы сүзтезмәләр составында киләләр. *Көч, җегәр* сүзләре исә нейтраль лексикага керә.

*Суынмадык:*
*Бездә әле* ***дәрман,***
*Бездә әле* ***җегәр*** *җитәрлек;*
*Әле тагын берәр ярты гасыр*
*«Эһ» тә итми гомер итәрлек!*
(«Барган саен еллар җылырак»)

Китапча һәм гомумкулланылыштагы сүзләр синонимлыгын түбәндәге мисаллар нигезендә дә күзәтеп була:

*Куркып тик мәңгелек хөкемнән,*
*Шүрләмәдең җирдә беркемнән.*
***Золым, җәза*** *күкрәп торганда,*
*Синең җырлау бушка булмады –*
*Ил, дәһшәттә, чын җыр тыңлады...*
(«...гә»)
*Монафикълык тулган һәрбер өйгә хәзер,*
***Намус, вөҗдан*** *кемдә бар соң, кемдә хәзер?!*
(«Газәлләр»)

Берәр синонимик рәтне алып карасак, андагы сүзләргә лингвистик анализ ясаганда, бу сүзләрнең стилистик кулланылышы һәм экспрессив (тойгы) бизәкләре ягыннан төрле булуын күрергә мөмкин. Без карап үткән мисалларда кулланылган китапча сүзләр шигырьнең пафосын, поэтик яңгырашын билгеләргә ярдәм итә. Кешенең эчке дөньясы белән бәйле абстракт төшенчәләрне белдерүче бу сүзләр поэтик лексикада бик еш очрый. Мондый

синонимик вариантларның булуын телнең алынмалар исәбенә баюы нәтиҗәсе итеп тә карарга мөмкин.

Сүздә теге яки бу әйбер, күренеш турында мәгълүмат кына бирелмичә, шуларга сөйләүченең мөнәсәбәте дә белдерелә. Атамага өстәлгән төшенчә теге яки бу эмоциональ-экспрессив төсмер барлыкка китерә. Бу хуплау, ярату, кимсетү, ирония, шаяру, иркәләү, көлү кебек мөнәсәбәтләр булырга мөмкин.

Эмоциональ-экспрессив сүзләр телдәге нейтраль лексикадан үзләренең өстәмә мәгънәләре һәм эмоциягә бай булулары белән аерылалар, фикерне ачык, төгәл итеп җиткерүгә хезмәт итәләр.

Синонимнарның бик күбесе, төп бер мәгънә белдергән хәлдә, әйбер яки күренешкә бәя бирүләре белән бер-берсеннән аерыла. XX йөз башларында гына халык телендә һәм әдәби әсәрләрдә *адәм* сүзе битараф функциядә – хәзергечә *кеше* дигән мәгънәдә йөргән. Бүгенге көндә исә *адәм* сүзе кешегә олы зат итеп карау булып яңгырый, бу сүз югары стиль сүзенә әйләнгән. *Бәндә* сүзендә исә кемне дә булса кимсетү, мыскыллау чагыла.

*Әкиятләре аша нурлар сибеп*
*Без барасы гомер юлына,*
*Өйрәтте ул безне кыюлыкка,*
***Бәндә** түгел, **адәм** булырга.*
(«Адымнар»)

Әлеге шигырь юлларында без сүзләрнең синонимик мөнәсәбәтләре катлауланып китеп, аларның бер-берсен алыштыру урынына, капма-каршы мөнәсәбәтләрне белдерә башлавын күрә алабыз. Хәсән Туфан *бәндә* һәм *адәм* сүзләрен очраштырып, соңгысына уңай мәгънә салган, шул рәвешле алар биредә синонимнар буларак түгел, ә антитеза чарасы булып кулланылалар.

Экспрессив-стилистик синонимнар сөйләмнең сурәтлелеген, яңгырашын көчәйтүдә зур урын тоталар. Алар еш кына авторның индивидуаль стиль үзенчәлекләре белән бәйле рәвештә кулланыла.

Гади сөйләм сүзләре татар теленең синонимнар байлыгын тәшкил итүдә зур роль уйныйлар. Әдәби телнең чигендә торсалар да, сурәтләү чарасы буларак, алар матур әдәбият әсәрләрендә гаять актив кулланылалар, сөйләмне төрләләндерәләр, сүзләр кабатлаудан коткаралар.

*«Шаһид булып карап торма, Идеал, –*
*Дидең, –* ***җәһәннәмгә кит, олак,***
*Минем «эш»не синнән башка гына*
*Башкарырга җирдә яхшырак...»*
(«Ильич синең төп сыйфатны»)

*Олак* сүзе әдәби тел нормалары чигендә торып, үзенең кискен һәм төксе әйтелүе белән аерылып тора. *Җәһәннәмгә кит* фразеологизмы да шигырь юлларына кискенлек төсмере бирә, гомумән, телнең гадилеген, халыкчанлыгын тәэмин итә. Әлеге синонимнар ачулануны, юкка чыгу-югалуны аңлаталар, башка мәгънәләрдә кулланылмыйлар.

Хәсән Туфан иҗатында фразеологизмнарны күпләп табып була. Алар арасында үзара синонимик мөнәсәбәтләргә кергәннәре дә бар.

*Юк,*
*Гаепләмим сезне, абыкайларым,*
*Зимагурлар, «алаканатлар»! –*
***Чын күңелдән*** *иде,* ***саф йөрәктән***
*Сез өйрәткән усал «сабак»лар.*
(«Бәйрәмгә килгәндә»)

*Чын күңелдән* фразеологик әйләнмәсе гомумкулланылышта йөри, ә *саф күңелдән* гыйбарәсе күбрәк югары стильгә карый. Әлеге фразеологик берәмлекләрне куллану шигырьнең образлылыгын арттыра.

Хәсән Туфан шигырьләрендә кулланылу активлыгы ягыннан стилистик синонимнар 15,1%ны тәшкил итә. Алар шигырь тукымасында үзләренә генә хас вазифаларны башкаралар. Стилистик синонимнарның кулланылышын тикшереп, без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. Сөйләүченең субъектив мөнәсәбәтен белдерүдә эмоциональ-экспрессив синонимнар әһәмиятле роль башкаралар.

2. Эмоциональ-экспрессив синонимнар сөйләмне тәэсирле, тирән мәгънәле итәләр, алар үзләренең хискә-тойгыга бай булулары белән аерылып торалар.

3. Экспрессив-стилистик синонимнар сөйләмнең сурәтлелеген, яңгырашын көчәйтүдә зур урын тоталар һәм еш кына авторның индивидуаль стиль үзенчәлекләре белән бәйле рәвештә кулланылалар.

4. Хәсән Туфан шигырьләрендә, сурәтләү чарасы буларак, гади сөйләм сүзләре дә синонимнар рәтендә кулланылалар. Алар шигъри сөйләмне төрләндерәләр, сүзләрне кабатлаудан коткаралар.

5. Экспрессив-стилистик синонимнарның күпчелеге фигыль сүз төркеме белән белдерелгән. Бу аларның күптөрле мәгънәләрне белдерүгә сәләтле булулары, синтаксик бәйләнешләрнең төрлелеге белән аңлатыла.

6. Мәгънә белән белдерелә торган эмоциональ тонны билгелиләр.

Әдәбият исемлеге:


1. Абдуллина Р.С. Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре .– Яр Чаллы: «КамАЗ» газета-кит. нәшр. – 127 б.

2. Бәширова И.Б. Сүз белән сурәт ясау. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1974. – 174 б.

3. Курбатов Х.Р. Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

4. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.

5. Сәлим, Х. Татар лексикологиясе. – Алабуга: АДПИ нәшр., 2002. – 40 б.

6. Хаков В.Х. Татар әдәби теле. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1999. – 304 с.